ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ШАДЧИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Молодежная, д.18, с. Шадчи,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422145

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ШӘДЧЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Яшьләр ур., 18 нче йорт, Шәдче авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422145

тел.(факс): (85563) 2-52-24; e-mail: Shad.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Постановление — Карар

№ 12 — 12 август 2020 ел

**Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының «Шәдче авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә балалар һәм яшьләр белән эшләү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019-2022 елларга Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2019 елның 5 мартындагы 158 нче карары, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы башкарма комитетының «2019-2022 елларга Мамадыш муниципаль районы балаларын һәм яшьләрен патриотик тәрбияләү» муниципаль программасы турында» 2019 елның 6 мартындагы 65 нче номерлы карары нигезендә, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Шәдче авыл җирлеге»муниципальберәмлеге Уставының 5 статьясының 1өлеше 12 пунктчасы, 50 статьясының 1 өлеше 8 пункты 1 пунктчасы нигезендә, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Шәдче авыл җирлеге»муниципаль берәмлегендәбалалар һәм яшьләр белән эшләү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру мәсьәләләрен хәл итүдә эшне нәтиҗәле оештыру максатларында Мамадыш муниципаль берәмлеге Шәдче авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1.Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының « Шәдче авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә балалар һәм яшьләр белән эшләү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру турынданигезләмәне кушымта нигезендә расларга.

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында (mamadysh.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Шәдче авыл җирлеге
Мамадыш муниципаль районының
Башкарма комитет җитәкчесе /В.В.Шрыков/

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль
районының Шәдче авыл җирлеге башкарма
комитетының 2020 елның 12 августы
11 нче карарына
Кушымта

# Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының «Шәдче авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә балалар һәм яшьләр белән эшләү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру турында Нигезләмә

## 1 статья. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019-2022 елларга Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2019 елның 5 мартындагы 158 нче карары, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы башкарма комитетының «2019-2022 елларга Мамадыш муниципаль районы балаларын һәм яшьләрен патриотик тәрбияләү» муниципаль программасы турында» 2019 елның 6 мартындагы 65 нче номерлы карары нигезендә, « Уставының 5 , 50 нче статьялары нигезендә эшләнде һәм муниципаль берәмлек территориясендә балалар һәм яшьләр белән эшләү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру формаларын һәм методларын билгели, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы  Шәдче авыл җирлеге»  муниципаль берәмлеге (алга таба - авыл җирлеге) яшьләренең үз-үзләрен тормышка ашыру һәм рухи-әхлакый тәрбияләү өчен хокукый, социаль-икътисадый һәм оештыру шартларын булдыруга һәм үстерүгә юнәлдерелгән.

## 2 статья. Балалар һәм яшьләр белән эшләү чараларын оештыруның һәм тормышка ашыруның максаты, бурычлары һәм принциплары

2.1. Балалар һәм яшьләр белән эшләү чараларын оештыруның һәм гамәлгә ашыруның төп максаты булып балаларның һәм яшьләрнең ихтыяҗларын һәм мәнфәгатьләрен канәгатьләндерү, балаларны һәм яшьләрне тулысынча үстерү һәм үз-үзләрен тормышка ашыру, аларның социаль һәм эшлекле активлыгын арттыру өчен шартлар тудыру тора.
2.2. Балалар һәм яшьләр белән эшләүнең бурычлары булып түбәндәгеләр тора:
- яшь гражданнар тарафыннан үзенең тормыш юлын сайлау өчен хокукый, социаль-икътисадый, оештыру шартлары тудыру;
- аларның социаль проблемаларын хәл итүне тәэмин итү, яшьләрнең ялын һәм мәшгульлеген оештыру, сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру өчен шартлар тудыру;

- балаларның һәм яшьләрнең социаль, мәдәни, рухи, патриотик һәм физик үсешенә ярдәм итү, аларның хокукларының төп гарантияләрен тәэмин итү;
- яшьләрнең иҗтимагый әһәмиятле инициативаларын гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыру;
- яшьләрне җәмгыятьнең социаль-икътисадый, сәяси һәм мәдәни тормышына кертү өчен шартлар тудыру.
2.3.Җирлектә балалар һәм яшьләр белән эшләү түбәндәге принципларга нигезләнә:
- яшьләр сәясәтен гамәлгә ашырганда җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең законлылыгы;
- социаль, мәдәни, рухи, патриотик, физик үсеш, тормыш юлын сайлау, белем алу, социаль-һөнәри эшчәнлеккә кертү, гаилә төзү, иҗтимагый әһәмиятле инициативаларны гамәлгә ашыру чорында муниципаль дәрәҗәдә балаларга һәм яшьләргә ярдәм күрсәтүнең өстенлеге;
- балалар һәм яшьләр белән эшләү чараларын гамәлгә ашыруда җирле үзидарә органнарының, физик һәм юридик затларның эшчәнлеген координацияләү;
- төрле социаль институтларның көчләрен берләштерүне күздә тоткан яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруга системалы, комплекслы якын килү.

## 3 статья. Балалар һәм яшьләр белән эшләү системасы

3.1. Җирлек территориясендә балалар һәм яшьләр белән эшләү системасы түбәндәгеләрне үз эченә ала:
- балалар һәм яшьләр ихтыяҗларын һәм мәнфәгатьләрен һәрьяклап канәгатьләндерүгә юнәлдерелгән программалар һәм хезмәтләр җыелмасы;
- җирлек һәм муниципаль учреждениеләрнең яшьләр белән эшләү буенча башкарма комитеты белән үзара бәйләнеше;
- балалар һәм яшьләр белән эшләү өлкәсендә программаларны гамәлгә ашыручы һәм хезмәтләр күрсәтүче башка милек рәвешләрендәге юридик затлар.

## 4 статья. Балалар һәм яшьләр белән эшләү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру өлкәсендә җирле үзидарә органнары вәкаләтләре

4.1. Балалар һәм яшьләр белән эшләү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру өлкәсендә җирле үзидарә органнары вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:
- мәдәният оешмалары хезмәтләрен ял итүне оештыру һәм тәэмин итү өчен шартлар тудыру;
-җирлек территориясендә физик культураны, мәктәп спортын һәм массакүләм спортны үстерү өчен шартлар тудыру, җирлекнең рәсми физкультура-савыктыру һәм спорт чараларын үткәрүне оештыру;
- балаларда һәм яшьләрдә гражданлык тәңгәллеген, югары патриотик аңны, Ватанга тугрылыкны формалаштыру, конституциячел вазыйфаларны, толерантлыкны, милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр культурасын үтәүгә әзер тору эшчәнлеген гамәлгә ашыру;

- республика, муниципаль балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләре эшчәнлегенә ярдәм итү;
- җирле үзидарә органы компетенциясенә керә торган мәсьәләләр буенча конкурслар, күргәзмәләр, ярминкәләр һәм башка чаралар оештыру һәм уздыру;
- Балалар һәм яшьләр делегацияләренең анда катнашу өчен юнәлешләрен оештыру;
фестивальләрдә, конкурсларда һәм башка чараларда, шул исәптән истәлекле вакыйгаларга һәм истәлекле даталарга багышланган;
- Россия Федерациясе законнарында, Татарстан Республикасы законнарында, муниципаль хокукый актларда каралган башка вәкаләтләр.

5 статья. Балалар һәм яшьләр белән эшләү чараларын оештыруның һәм гамәлгә ашыруның финанс нигезләре

5.1. Балалар һәм яшьләр белән эшләү чараларын финанс белән тәэмин итү Россия Федерациясе законнары, Татарстан Республикасы законнары, муниципаль хокукый актлар нигезендә гамәлгә ашырыла.
5.2. Балалар һәм яшьләр белән эшләү эшчәнлеген финанслау җирлек бюджеты, шулай ук законнар белән тыелмаган башка өстәмә чыганаклар хисабына үтәлергә тиешле чыгым йөкләмәсе булып тора.
5.3. Җирлектә балалар һәм яшьләр белән эшләү чараларын оештыру балалар һәм яшьләр белән эшләү буенча комплекслы һәм максатчан муниципаль программаларны, шулай ук программаларда һәм ярдәмче программаларда бүлекләрне эшләү һәм тормышка ашыру рәвешендә гамәлгә ашырыла ала.